РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 37

2017 елның 13 марты

# 2017 елның язгы чорында муниципаль автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 8 ноябрендәге «Автомобиль юллары һәм Россия Федерациясендә юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, 2013 елның 31 маендагы «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 372 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, 2017 елның язгы чорында артык дымлылык нәтиҗәсендә автомобиль юлы конструктив элементларының ныклыгын тәэмин итү мөмкинлеге кимү белән бәйле рәвештә карар бирәм:

1. 2017 елның 15 апреленнән 14 маена кадәр Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында күчәргә яки күчәрләр төркеменә (арбага) рөхсәт ителгән иң чик йөкләнештән артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

1.1. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап хәрәкәт, махсус рөхсәт язуын рәсмиләштереп, Түбән Кама шәһәренең автомобиль юлларына китерелгән зыянны каплаган очракта гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чорга транспорт чарасының һәр күчәренә яки күчәрләр төркеменә (арбага) рөхсәт ителгән түбәндәге иң чик йөкләнешне расларга:

1) бер күчәрле – 6,0 тонна;

2) ике күчәрле арба – 5,0 тонна

3) өч күчәрле арба – 4,0 тонна.

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы гамәлләр түбәндәгеләргә кагылмый дип билгеләргә:

1998 елның 24 июлендәге 127-ФЗ номерлы «Халыкара автомобиль ташуларын гамәлгә ашыруга дәүләт контроле һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» Федераль закон Нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган халыкара йөк ташу;

автобусларда пассажирлар йөртү, шул исәптән халыкара;

азык-төлек продуктларын, хайваннарны, дару препаратларын, орлык фонды, ашламалар, почта һәм почта йөкләрен ташу (әлеге абзацта күрсәтелмәгән йөкләр белән бергә ташудан тыш);

ягулык ташучы (бензин, дизель ягулыгы, суднолар ягулыгы, реактив двигательләр өчен ягулык, ягулык мазуты, газ ягулыгы) йөк күтәрүчәнлеге 16 тоннага кадәр булган транспорт чаралары;

табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле йөкләрне ташу;

төбәк әһәмиятендәге һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсе белән килешү буенча Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатация техникасын һәм материалларны ташу;

федераль закон буенча хәрби хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнарының транспорт чаралары.

4. Түбән Кама шәһәре территориясендә җаваплы оешмалар һәм учреждение җитәкчеләренә тәэмин итәргә (оештырырга):

- Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгәнчә, Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында күчәргә яки күчәрләр төркеменә (арбага) рөхсәт ителгән иң чик йөкләнештән артып киткән, йөкле яисә йөксез транспорт чаралары хәрәкәтенә махсус рөхсәтләрне үз вакытында бирү;

- Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга Интернет челтәрендәге сайтларда, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша мондый чикләүләрнең сәбәпләре һәм сроклары турында үз вакытында хәбәр итү;

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгәнчә, төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә өстәмә мәгълүмат билгеләре белән тиешле юл билгеләрен урнаштыру.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсенеңТүбән Кама районы буенча Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте иминлеген саклауны контрольдә тотуны һәм үлчәү контроле постлары урнашкан урыннарда кизү торуны тәкъдим итәргә.

6. Түбән Кама шәһәре территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында йөргән өчен зыянны каплау исәбенә түләнгән акчалар 40101810800000010001 исәп-хисап счетына күчерелә дип билгеләргә. Алучы банкы: Татарстан Республикасы Милли банкы бүлекчәсе, алучы банкның БИКы: 049205001. Алучы - ТР буенча ФКИ («Бюджет һәм финанслар департаменты» МКУ), ИНН 1651044909, КПП 165101001, ОКТМО 92644000,

бюджет классификациясе коды: 814 1 16 37 040 05 0000 140.

7. Әлеге карарны «Нижнекамская Правда», «Туган Як» газеталарында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары Д.И.Баландин